РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Глава
Уразаевского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района
ул. Н.Бадертдинова , д. 35, село Уразаево,
Азнакаевского муниципального района РТ
423303

Тел./факс(885592)43-5-55;

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Уразай авыл җирлеге
башлыгы
Н.Бэдретдинов ур., 35нче йорт, Азнакай
районы, Уразай авылы, 423303
E-mail: Uraz.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«07» ноябрь 2025 ел **№ 2**

2026 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең Уразай торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай мунициипаль районының Уразай авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең Уразай торак пунктында теркәлгән, сайлау хокукына ия булган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Уразай авыл җирлегенең Уразай торак пунктында 2025 елның 17 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта гражданнар җыенын үткәрергә.

2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең Уразай торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп -Татарстан Республикасы Азнакай мунициипаль районы Уразай авыл җирлеге Башкарма комитетын;

- гражданнар җыенын үткәрү вакыты-2025 елның 17 ноябрендә 15.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр;

– гражданнар җыенын уздыру урыны - Уразай авылы, Энгельс урамы, 63 йорт, Уразай авылы мәдәният йорты залы;

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2025 елның 07 ноябреннән дә соңга калмыйча, гражданнарга Татарстан Республикасы Азнакай мунициипаль районының Уразай авыл җирлеге Башкарма комитетында түбәндәге адрес буенча гражданнар җыены карарына чыгарыла торган

материаллар белән танышу хокукын тәэмин итәргә: Уразай авылы, Н.Бәдертдинов ур., 35.;

- сайлау хокукына ия Уразай торак пунктында яшәүчеләрнең исемлекләрен төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Уразай торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән гражданнар җыены турында хәбәр итәргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:
Сез, "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең Уразай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, кондезге бүлектә белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда 400 сум күләмендә, 2 төркем инвалидларга, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерларга, күпбалалы гаиләләргә бер тапкыр түләнә торган түләүне киметеп, 200 сум күләмендә, үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы?

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (урам яктырткычларындагы лампаларны алмаштыру, яктырткычларны сатып алу һәм урнаштыру);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Садовая,Н.Бэдертдинова урамнары шартнамәсе буенча вак таш сатып алу, төяү, ташу, салу, эшләр өчен түләү);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (чүп үләнен чаптыру, чүп җыю, балалар мәйданчыкларын, ял итү зоналарын карап тоту, автомобиль юлын кардан чистарту, трактор очен роторлы чапкыч сатып алу).

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә http://aznakaevo.tatar.ru. һәм түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында:

- Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Уразай авылы., Н. Бәдертдинов ур., 35. урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык: Д.И. Мотыйгуллина

УРАЗАЕВСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ